РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

***Постановление*** ***Карар***

**09.12.2025** **г. Чистополь** **79**

Ачык тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 16:42:010201:485 кадастр номерлы, 275 кв. м. мәйданлы, түбәндәге адрес буенча урнашкан җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Олы Талкыш авыл җирлеге, Кызылъяр авылы, Кызылъяр урамы, 16 «А» - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Олы Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1) «җәмәгать тукланувы».
2. Ачык тыңлауларны оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:
1) Э.Р. Хәсәнов – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;
2) П.Б. Емельянов – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;
3) В.О. Маркин – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Шәһәрне җайга салу һәм инфраструктура үсеше» МБУ төзелеш контроле бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча);
4) А.А. Шумилов – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы;
5) М.Ю. Исхакова – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе;
6) Ф С. Хәйруллина - Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча Чистай, Спас районнарындагы ТОУ башлыгы (килешү буенча);
7) А.Ю. Камашев – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы;
8) Э.Б. Ильин - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Олы Талкыш авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча).
3. Ачык тыңлауларны оештыручыга-коллегиаль киңәшмә органына ачык тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.
4. Ачык тыңлаулар үткәрү 2026 елның 3 гыйнварыннан дә соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д. А. Иванов

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар башлану турында хәбәрнамә

1. 16:42:010201:485 кадастр номерлы, 275 кв мәйданлы, түбәндәге адрес буенча урнашкан җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар башлануы хакында хәбәр итәбез: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Олы Талкыш авыл җирлеге, Кызылъяр авылы, Кызылъяр урамы, 16 «А» - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Олы Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1) «җәмәгать туклануы» (алга таба – проект).

2. Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

- Гариза;
- Күчемсез мөлкәтнең дәүләт реестрыннан өземтә;
- Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләреннән 13.12.2023 № 27/14 схемасы;

3. Проект буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:

Проект буенча ачык тыңлаулар 2025 елның 12 декабреннән 2025 елның 23 декабренә кадәр уздырыла.

Ачык тыңлаулар үткәрү процедурасына түбәндәге этаплар керә:

- ачык тыңлауларның башлануы турында хәбәр итү;
- проектны һәм мәгълүмат материалларын аның янына рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;
- ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышларын үткәрү;
- ачык тыңлауларның беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

4. Ачык тыңлауларда катнашучылар даирәсе:

Проект буенча ачык тыңлауларда түбәндәге гражданнар катнаша:

- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының "Олы Талкыш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре.

5. Ачык тыңлаулар үткәрелә торган территория:

- Россия Федерациясе Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының "Олы Талкыш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе

6. Проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы:

- Татарстан Республикасы Олы Талкыш авыл җирлегенең "Кызылъяр төп гомуми белем бирү мәктәбе" филиалы бинасында, адресы: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Олы Талкыш авылы, Пришкольная урамы, 2Б йорт - 2025 елның 12 декабре.

7. Проект экспозицияләрен үткәрү сроклары:

2025 елның 12 декабреннән 2025 елның 23 декабренә кадәр.

8. Экспозицияләрне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:

Эш көннәрендә 09.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш тәнәфесе – 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

9. Ачык тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше:

2025 елның 12 декабреннән 2025 елның 23 декабренә кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ ГрК) $5^1$ статьясының 12 өлеше нигезендә идентификация узган ачык тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- Чистай муниципаль районының рәсми сайты аша;
- ачык тыңлауларны оештыручы адресына язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә, Татарстан Республикасы Олы Талкыш авыл җирлегенең "Кызылъяр төп гомуми белем бирү мәктәбе" филиалы бинасында, адресы: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Олы Талкыш авылы, Пришкольная урамы, 2Б йорт, (84342) 4-66-87 (9.00 дән 17.00 гә кадәр);
- түбәндәге адрес буенча ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу китабында (журналында) язу юлы белән: Татарстан Республикасы Олы Талкыш авыл җирлегенең "Кызылъяр төп гомуми белем бирү мәктәбе" филиалы бинасында, адресы: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Олы Талкыш авылы, Пришкольная урамы, 2Б йорт. (84342)4-66-87 (9.00 дән 17.00 гә кадәр).

Ачык тыңлауларда катнашучылар: РФ ГрК $5^1$ статьясының 12 өлеше нигезендә идентификация узган, ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышларын үткәрү барышында тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне язмача яисә телдән кертергә хокуклы.

10. Ачык тыңлауларны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат: проект буенча ачык тыңлауларны 2025 елның 24 декабрендә уздырырга:

- Татарстан Республикасы Олы Талкыш авыл җирлегенең "Кызылъяр төп гомуми белем бирү мәктәбе" филиалы бинасында, адресы: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Олы Талкыш авылы, Пришкольная урамы, 2Б йорт, 14:00.

11. Проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат:

Проект Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) 2025 елның 12 декабреннән https://chistopol.tatarstan.ru/publichnie-slushaniya-847337.htm сылтамасы буенча урнаштырылачак.

12. Әлеге хәбәрнамәне Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Чистай Башкарма комитеты
җитәкчесе урынбасары П. Б. Емельянов

**Правила Землепользования и застройки муниципального образования «Большетолкишское сельское поселение» Чистопольского муниципального района от 13.12.2023 №27/14**




Земельный участок: 16:42:010201:485

Информация | Сервисы | Объекты | Части ЗУ | Состав

| | |
|---|---|
| Вид объекта недвижимости | Земельный участок |
| Вид земельного участка | Землепользование |
| Дата присвоения | 07.08.2024 |
| Кадастровый номер | 16:42:010201:485 |
| Кадастровый квартал | 16:42:010201 |
| Адрес | Российская Федерация, Республика Татарстан, Чистопольский муниципальный район, Большетолкишское сельское поселение, с Красный Яр, ул. Красноярская, 16 "А" Свернуть |
| Площадь уточненная | 275 кв. м |
| Площадь декларированная | - |
| Площадь | - |
| Статус | Учтенный |
| Категория земель | Земли населенных пунктов |
| Вид разрешенного использования | для строительства кафе-бистро |

Зона индивидуальной жилой застройки (Ж1)

# Генеральный план муниципального образования «Большетолкишское сельское поселение» Чистопольского муниципального района







- Зона застройки индивидуальными жилыми домами
- Многофункциональная общественно-деловая зона

ЗОУИТ: – 3 пояс зоны санитарной охраны водозабора для питьевого и хозяйственно-бытового водоснабжения н.п. Красный Яр, Большетолкишского сельского поселения Чистопольского муниципального района РТ

## Градостроительный регламент зон индивидуальной жилой застройки (Ж1)

| Вид разрешенного использования | | Предельные размеры земельных участков и предельные параметры ра… реконструкции объектов капитального строител… | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Код** | **Наименование** | **размер земельного участка, кв.м** | **количество этажей / высота строения** | **максимальный процент застройки** | **мин…** |
| **Условно разрешенные виды разрешенного использования** | | | | | |
| 4.1 | Деловое управление | н.у. | н.у. | н.у. | н.у. |
| 4.4 | Магазины | н.у. | 3 этажа/н.у. | н.у. | н.у. |
| 4.5 | Банковская и страховая деятельность | н.у. | 2 этажа/н.у. | н.у. | н.у. |
| 4.6 | Общественное питание | н.у. | 2 этажа/н.у. | н.у. | н.у. |
| 4.7 | Гостиничное обслуживание | н.у. | 3 этажа/н.у. | н.у. | н.у. |